Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Кукмара шәһәре Советы

# КАРАР

2019 елның 30 декабре № 31

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районыКукмара шәһәремуниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

I. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяда:

1 өлешнең 22 пунктында «документациясен раслау,» сүзләреннән сон «җмрлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү,” сүзләрен өстәргә;

1.2. 6 статьяда:

1 өлешнең 13 пунктында «күзәтүчесез хайваннарны тоту һәм карап тоту буенча чаралар» сүзләрен «яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлек» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 29 статьяда:

а) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Депутат «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, бурычларны үтәргә тиеш. «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар

(кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акчаларны һәм кыйммәт әйберләрне саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләр, тыюлар, вазыйфалар үтәлмәгән очракта, әгәр «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкача каралмаган булса, депутатның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла».

б) түбәндәге эчтәлекле 7 өлешен өстәргә:

«7. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән депутатка, әгәр бу мәгълүматны бозып күрсәтүләр җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чараларын кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында үз вәкаләтләре вакыты туктатылганчыга кадәр муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында вазыйфа биләүдән азат итү;

3) вәкаләтләре вакыты туктатылганчы, даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү белән даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында аның вәкаләтләре срогы туктатылганчы вазыйфа биләүне тыю;

5) вәкаләтләр срогы туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләрне үтәүне тыю.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 8 өлешен өстәргә:

«8. Депутатка карата әлеге статьяның 7 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.»;

1.4. 48 статьяда:

а) 1 өлешендәге 4 пунктның өченче абзацында «торак биналарны үзгәртеп планлаштыру» сүзләрен «күпфатирлы йорттагы биналарны» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешнең ундүртенче абзацында «яшәүче күзәтүчесез хайваннарны тоту һәм карап тоту чаралары» сүзләрен «яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеге» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 86 статьяның 2 өлешентүбәндәгередакциядәбәянитәргә:

«1. Муниципаль бурычалулар дигәндә муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне урнаштыру юлы белән һәм заемчы буларак гавами-хокукый берәмлекнең бурыч йөкләмәләре барлыкка килә торган кредитлары рәвешендә гавами-хокукый берәмлек исеменнән гавами-хокукый берәмлек бюджетына заем акчаларын җәлеп итү аңлашыла.»;

1.6. 89 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль финанс контроле бюджет-хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы хокукый актларның, гавами норматив йөкләмәләрне һәм Россия

Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан физик затларга башка түләүләр буенча йөкләмәләрне билгели торган хокукый актларның нигезләмәләрен үтәүне, шулай ук бюджеттан акча бирү турында дәүләт (муниципаль) контрактлар, шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәүне тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.»;

б) 2 өлештә «бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

11. Әлеге карар, үз көченә керүнең башка вакытлары законнар белән каралмаган булса, дәүләт теркәвенә алынганнан соң рәсми игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Кукмара шәһәре Мэры С. Д. Димитриев